ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15 сентября 2026г. № 9548

Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 бүлекнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының «Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Чаллы» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2018 елның 29 августындагы 4821 номерлы Карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» вакытлы матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2026 елның 15 сентябрендәге
9548 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Чаллы» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Физкультура-сәламәтләндерү хезмәтенең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәя, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Көндезге парковка (җиңел автомобиль) | машина урыны сәгать | 50,00 |
| 2 | Төнге парковка 18.00 дән 8.00 гә кадәр (җиңел автомобиль) | машина урыны сәгать | 100,00 |
| 3 | Тәүлек буе парковка (җиңел автомобиль) | машина урыны ай | 1500,00 |
| 4 | Көндезге парковка (Газель, автобус, ПАЗ) | машина урыны сәгать | 100,00 |
| 5 | Төнге парковка 18.00 дән 8.00 гә кадәр (Газель, автобус, ПАЗ) | машина урыны сәгать | 200,00 |
| 6 | Тәүлек буе парковка (Газель, автобус, ПАЗ) | машина урыны ай | 3000,00 |
| 7 | Сәламәтләндерү үзәге хезмәтләре | сәгать | 1000,00 |
| 8 | Тренажер залы хезмәтләре бер тапкыр килү | сәгать | 300,00 |
| 9 | Тренажер залы хезмәтләре 12 тапкыр шөгыльләнүгә абонемент | месяц | 1800,00 |
| 10 | Тимераякта массакүләм шуу бер тапкыр килү | сәгать | 250,00 |
| 11 | Тимераякларны прокатка бирү | сәгать | 50,00 |
| 12 | Тимераякларны үткенләү | пара | 250,00 |
| 13 | Фигуралы шуу буенча төркемнәрдә шөгыльләнү | 45 минут | 250,00 |
| 14 | Хоккей буенча төркемнәрдә шөгыльләнү | 45 минут | 250,00 |
| 15 | Ял көне төркемнәрендә шөгыльләнү (тимераякта шуу) | 45 минут | 300,00 |
| 16 | Фигуралы шуу буенча индивидуаль шөгыльләнү | 45 минут | 1000,00 |
| 17 | Хоккей буенча индивидуаль шөгыльләнү | 45 минут | 1000,00 |
| 18 | Хореография залында шөгыльләнү | 45 минут | 250,00 |
| 19 | Спорт корылмасы хезмәте | сәгать | 1000,00 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ачык хоккей корты (чишенү бүлмәсе белән) | | |
| 20 | Спорт корылмасы хезмәте корпоратив шуу өчен боз аренасы (НХЛ) | сәгать | 6000,00 |
| 21 | Спорт корылмасы хезмәте 100 кешегә кадәр массакүләм корпоратив шуу өчен боз аренасы | сәгать | 25000,00 |
| 22 | Спорт корылмасы хезмәте театр-тамаша чаралары (концертлар, бозда шоу) | сәгать | 32000,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева